ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Җир кодексының $33^{3}$ статьясына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 11 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексының $33^{3}$ статьясындагы 3 пунктына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 1999, № 8 (I өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) акчалары күпфатирлы йорт төзелешенә җәлеп ителгән, намуссыз застройщиклар гамәлләреннән (гамәл кылмауларыннан) зыян күргән гражданнарга ярдәм итү чаралары күрү (Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{6}$ статьясындагы 2 пунктының $3^{1}$ пунктчасы нигезендә җир кишәрлеге бирү очракларыннан тыш);»;

2) 5 пунктчада «намуссыз застройщиклар гамәлләреннән (гамәл кылмауларыннан) зыян күргән затларга, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 06 август
№ 66-ТРЗ